КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 11 июль г.Казань № 563

Татарстан Республикасының Яшьләр
эшләре министрлыгы мәсьәләләре

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын үзгәртеп кору турында» 2018 ел, 22 июнь, ПУ-454 нче Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәне һәм аның структурасын расларга.
2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи эш хаклары буенча 903,183 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 42 берәмлек дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына өч министр урынбасарын булдыруны рөхсәт итәргә.
4. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына бу карарны тормышка ашыруга бәйле булган чыгымнарны «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 ел, 30 ноябрь, ТРЗ-85 нче Татарстан Республикасы Законы белән күздә тотылган акча чикләрендә финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә.
5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 11 июль, 563 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы тармак компетенциясендәге Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора.

1.2. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таяна.

1.3. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә эшчәнлекне федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыра.

1.5. Министрлык юридик зат була, аның үз исеме язылган һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән мөһере, законнар белән билгеләнгән тәртиптә ачыла торган хисап исәпләре һәм башка исәпләре бар.

1.6. Министрлыкның урнашу урыны (юридик адресы): 420107, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 5 нче йорт.

## 2. Министрлыкның бурычлары

Министрлыкның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт яшьләр сәясәтен үстерүнең һәм аларны тормышка ашыруның өстенлекле юнәлешләрен һәм стратегиясен билгеләү;

яшьләргә социаль ярдәм күрсәтү;

дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә проектларны тормышка ашыруда юридик һәм физик затларга дәүләт ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

яшьләрне һәрьяклап үстерү, аның потенциалын тормышка ашыру өчен шартлар булдыру;

яшьләрне актив социаль практикага җәлеп итү өчен шартлар тудыруга, яшьләрнең актуаль мәсьәләләрен хәл итүгә һәм яшьләрнең позитив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру.

## 3. Министрлыкның функцияләре

3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә – дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү (04.07 <*>)[1] һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.16 <*>).

3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән – бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.02.3 <*>) функциясен гамәлгә ашырганда;

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01 <*>);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03 <*>);

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән – мәгълүматлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15 <*>);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү (01.12 <*>);

мәгариф белән идарә итү (04.05 <*>);

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

мәдәният (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихый-мәдәни мирасны саклау һәм алардан файдалану) өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу, төрле диннәрдә булган дини берләшмәләр арасында үзара аңлашуны һәм түземлелекне ныгытуга ярдәм итү (04.03 <*>);

иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.16 <*>);

Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

сәламәтлек саклау белән идарә итү (04.02 <*>);

---

[1] Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы

Татарстан Республикасында халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү (04.02.13 <*>);

Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән – авыл хуҗалыгы белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02 <*>);

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

архитектура эше белән идарә итү (01.04 <*>);

территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләүне тәэмин итү (01.05.2 <*>);

объектларны төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү белән идарә итү (01.05.05 <*>);

гражданнарның торакка хокукын тәэмин итү белән идарә итү (04.01.02 <*>);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01 <*>);

Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы белән – физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04 <*>);

Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән – муниципальара һәм шәһәр яны элемтәсендә һава, су, автомобиль транспорты белән (җиңел таксины кертеп (рөхсәтнамә бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәтнамәнең дубликатын бирү, рөхсәтнамә гамәлен вакытыннан алда туктату, Бирелгән рөхсәтнамәләр реестрын алып бару өлешендә) һәм шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру, җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тоту функцияләрен гамәлгә ашырганда (03.03.02 <*>);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән – Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәттән (биналар, корылмалар), транспорттан, җиһазлардан, мәдәни мирас объектларыннан файдалану белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07.01 <*>);

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (01.13 <*>);

иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.16 <*>);

хәйрия эшчәнлеге өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.17 <*>);

социаль яклау белән идарә итү (04.06 <*>);

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалар эшләү (01.01 <*>);

инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу (01.10 <*>);

инновация эшчәнлеген үстерү белән идарә итү (01.11 <*>);

Татарстан Республикасының ведомстволарга караган дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2 <*>);

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлек белән идарә итү (01.03 <*>);

сәнәгать белән идарә итү (03.01 <*>);

эчке товар базарының аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешен җайга салу (03.05 <*>);

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән – җитештерү билгеләнешендәге продукциягә, товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) билгеләнгән тәртиптә җайга салу функциясен гамәлгә ашырганда (01.09.02 <*>);

Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча дәүләт комитеты белән – архив эшләре белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03 <*>);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1 <*>);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән – дәүләт-шәхси партнерлык һәм шәхси инвестицияләр өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.18 <*>);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе белән – балигъ булмаганнарның караучысыз калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.06.03 <*>);

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән – иҗтимагый тәртип саклауны тәэмин итү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.02 <*>).

3.3. Министрлык бу Нигезләмәнең 3.1 нче, 3.2 нче пунктлары нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) дәүләт яшьләр сәясәте үсешенә комплекслы анализ ясауны һәм аны фаразлауны тәэмин итү;

2) яшьләр проблемаларын хәл итү өлешендә дәүләт социаль-икътисадый сәясәтен эшләүдә, килештерүдә һәм тормышка ашыруда катнашу, шул исәптән яшьләр сәясәтен әзерләү, аның стратегиясен һәм аны үстерү концепцияләрен килештерү;

3) яшь буында гражданлык һәм патриотлык хисен тәрбияләү системасын формалаштыру һәм үстерү, яшь гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүдә булышлык күрсәтү;

4) балаларның һәм яшьләрнең иҗтимагый берләшмәләре проектларына һәм программаларына булышлык күрсәтү чараларын эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру;

5) балалар һәм яшьләр өчен ял итү лагерьларында юнәлешле сменалар оештыру;

6) яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итү, социаль тискәре күренешләрне профилактикалау буенча шартлар тәэмин итү һәм чараларны тормышка ашыру;

7) яшьләр инфраструктурасын үстерүдә катнашу, дәүләт оешмаларының яшьләр белән эшләү буенча эшчәнлеген камилләштерү;

8) дәүләт учреждениеләренең матди-техник базасын үстерү;

9) дәүләт ярдәменнән файдаланучы Яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең республика реестрын формалаштыру һәм алып бару;

10) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт социаль нормаларын, нормативларын һәм стандартларын эшләүдә катнашу һәм аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыру;

11) яшьләр өчен формаль булмаган белем бирү институтларын, формаларын камилләштерүдә катнашу;

12) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә статистика исәбен һәм хисаплылыкны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

13) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне фәнни, аналитик, методик яктан тәэмин итү системасын оештыру һәм камилләштерү;

14) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә махсуслашкан кадрларны әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

15) дәүләт яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча һәр граждан өчен ачык булган мәгълүмат ресурсларын булдыруда булышлык күрсәтү;

16) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлекне оештыру һәм үстерү;

17) яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә һәм аларның инициативаларына булышлык күрсәтү, Министрлык бурычларын тормышка ашырганда үзара хезмәттәшлекне оештыру;

18) җирле үзидарә органнары белән дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә бергәләп эшләү турында килешүләр әзерләүне, төзүне тәэмин итү;

19) җирле үзидарә органнарының дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаруын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру;

20) яшьләрнең мобилизация һәм хәрби хезмәткә кадәрге әзерлеген оештыруда һәм тәэмин итүдә катнашу, Министрлыкның, эшчәнлекләре Министрлык эшчәнлегенә бәйле булган яки аның карамагы өлкәсендәге оешмаларның мобилизация әзерлеген һәм мобилизациясен оештыру һәм тәэмин итү, шулай ук бу чараларны методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыру;

21) дәүләт һәм ведомство максатчан программаларын килештерү, шулай ук дәүләт яшьләр сәясәтенә кагылышлы муниципаль программаларны, шул исәптән капитал салулар программаларын әзерләүдә катнашу;

22) һөнәри белем бирү оешмаларына һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларына кабул итүнең контроль саннарын формалаштыруда катнашу;

23) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә белгечләр әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучылар өчен компетенцияләр паспортларын әзерләүдә катнашу;

24) Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт агентлыгы өчен дәүләт йөкләмәләрен формалаштыруда катнашу;

25) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә түбәндәге юллар белән конкуренцияне үстерү:

25.1) республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә яшьләр эшмәкәрлеген үстерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

25.2) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә иҗтимагый оешмалар һәм дәүләткә карамаган оешмалар челтәрен үстерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

26) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең кеше капиталы буларак яшьләр потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру өчен шартлар тудыру турында тәкъдимнәр булдыру һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү;

27) үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче мәгариф оешмаларының өченче буын университеты моделенә күчү стратегияләрен әзерләүдә һәм тормышка ашыруда катнашу;

28) яшьләр хәрәкәтен үстерү өлкәсендә дини оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

29) ведомство буйсынуындагы социаль өлкәгә караган учреждениеләр челтәрен оптимальләштерүдә катнашу;

30) Татарстан Республикасы Президентының кадрлар резервында катнашучылар, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округлары башлыклары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары өчен чыгарылыш эшләр темалары турында тәкъдимнәр әзерләү;

31) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен (алга таба – учреждениеләр) гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкару, шул исәптән:

учреждениеләрне оештыру, үзгәртеп оештыру, тибын үзгәртү, бетерү турында карарлар проектларын әзерләү, аларның уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү;

учреждениеләргә эшчәнлекнең учреждение уставы белән күздә тотылган төп төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм раслау;

учреждениеләрне гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкару;

учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары проектларын эшләү;

учреждениеләр тарафыннан фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне ел саен бәяләү;

учреждениеләр эшчәнлегенең учреждениеләр эшчәнлеген бәяләү буенча билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәүне бәяләү;

32) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру;

33) урта һөнәри һәм югары белем бирү һөнәрләре һәм белгечлекләре буенча квалификацияле белгечләрне тармакта әзерләү ихтыяҗы фаразын формалаштыруны оештыру;

34) Татарстан Республикасының фәнни-белем бирү кластерларында белгечләр әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүгә дәүләт заказына тәкъдимнәр формалаштыру;

35) тармакны кадрлар белән тәэмин итү торышын өйрәнү, кеше капиталын үстерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

36) Татарстан Республикасында дини һәм милли сәбәпләр аркасында килеп чыга торган низагларны алдан кисәтү һәм милләтара һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләр мониторингының комплекслы системасы кысаларында үз компетенциясе чикләрендә мәгълүмат җыюны һәм аны дәүләт сәясәтен тормышка ашыручы һәм милли сәясәт өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органына кертүне гамәлгә ашыру;

37) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмаларының студентлар отрядлары эшчәнлеген үстерүдә катнашу һәм аларның үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру;

38) һөнәри һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучыларның тәрбия эшләре буенча структуралары эшен яраштыру өчен шартлар тудыру;

39) иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруда катнашу;

40) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, алар ведомствосы буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренең иреклеләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручылар, иреклеләр (волонтерлар) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен әзерләү;

41) иреклеләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручыларга, иреклеләр (волонтерлар) оешмаларына (шул исәптән аларның дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлегендә), иреклеләргә (волонтерларга), коммерциягә карамаган социаль юнәлештәге оешмаларга, иреклеләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручыларга, иреклеләр (волонтерлар) оешмаларына оештыру, мәгълүмати, методик яктан һәм башка ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә ярдәм күрсәтү;

42) иреклеләр (волонтерлар) эшчәнлеген популярлаштыру;

43) иреклелеккә (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралары булган муниципаль программаларга (ярдәмче программаларга) булышлык күрсәтү;

44) җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү чараларын әзерләүдә һәм тормышка ашыруда булышлык күрсәтү һәм аларга методик яктан ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

45) иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә Министрлык каршында төзелә торган яраштыру органнарын һәм киңәшмә органнарны формалаштыру;

46) дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны формалаштыру;

47) планлаштырыла торган елга бюджет турындагы Татарстан Республикасы законы проектын әзерләүдә катнашу;

48) дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруга финанс чаралары белән эш итү;

49) Министрлык, шулай ук ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеге буенча бухгалтерлык һәм статистика хисаплылыгын билгеләнгән вакытларда тапшыру;

50) гражданнарның Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен законнар белән билгеләнгән вакытларда карап тикшерү;

51) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә мәгълүмат һәм нәшрият эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

52) дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендәге федераль законнар нигезендә электрон мәйданчык операторына вәкаләтле орган исеменнән эш итәргә хокуклы затның электрон санлы имзасы куелган, заказчы имзалаган контракт күчермәсен җибәрү;

53) үз компетенциясе чикләрендә экстремизм эшчәнлегенә һәм террорчылыкка каршы торуда катнаша, Министрлыкка беркетелгән объектларның террорчылыктан сакланган булуын тәэмин итү;

54) террорчылыкка каршы тору чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне көчәйтү максатларында укуларда катнашу;

55) үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россиянең һәм чит илләрнең башка органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләрнең, килешүләрнең һәм ачык-хокукый характердагы башка актларның реестрын алып бару;

56) ел саен Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру буенча махсус дәүләт органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру турында хисап кертү;

57) үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә гражданнарга телдән һәм язмача хокукый консультация бирү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү;

58) федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый

характердагы башка документлар язу рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм судларда, дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда граждан мәнфәгатьләрен яклау;

59) Министрлыкка һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә беркетелгән объектларның террорчылыктан сакланган булуына карата таләпләрнең үтәлүен оештыру һәм тәэмин итү;

60) Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча законнар һәм башка норматив актлар проектларын әзерләү, законнар мониторингын гамәлгә ашыру.

3.4. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәге хокукларга ия:

дәүләт яшьләр сәясәтенә караган дәүләт учреждениеләре системасындагы дәүләт милкәте белән эш итү мәсьәләләрен дәүләт милкәте белән идарә итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы белән билгеләнгән тәртиптә килештерергә;

дәүләт оешмаларын, аларның филиалларын һәм вәкиллекләрен билгеләнгән тәртиптә оештыру, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарыннан, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарыннан, юридик һәм физик затлардан Министрлык компетенциясенә керә торган һәм яшьләргә кагылышлы булган мәсьәләләр буенча мәгълүмат соратып алырга;

үз вәкаләтләре чикләрендә чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре белән халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук бу максатлар өчен махсус төзелгән органнар кысаларында халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнашырга;

ведомство бүләкләрен раслау, алар белән яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында карарлар кабул итәргә һәм бүләкләүнең башка төрләрен кулланырга;

Министрлыкка норматив хокук актлары белән беркетелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырга.

## 4. Министрлык эшчәнлеген оештыру

4.1. Министрлыкка Татарстан Республикасы Конституциясе билгеләгән тәртиптә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган министр җитәкчелек итә.

4.1.1. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Министр:

аның тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган урынбасарлары була;

Министрлык эшчәнлегенә бер үзе идарә итә торган гомуми җитәкчелек гамәлгә ашыра һәм Министрлыкка йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен шәхсән җавап бирә;

хезмәткәрләрнең билгеләнгән саны, хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә Министрлык аппаратын тоту өчен чыгымнар сметасын, штат расписаниесен раслый;

үз компетенциясе чикләрендә билгеләнгән тәртиптә боерыклар чыгара, кагыйдәләр, тәгълимнамәләр, нигезләмәләр раслый (кирәк булган очракларда – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары белән берлектә), аларны үтәү турында күрсәтмәләр бирә һәм тикшерүдә тотуны оештыра;

Министрлык аппараты һәм аның структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең вазыйфаи тәгълимнамәләрен раслый;

Министрлык аппараты хезмәткәрләрен билгеләнгән тәртиптә вазыйфаларына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә;

үзләрен аеруча яшы яктан күрсәткән хезмәткәрләрне мактаулы исемнәр бирүгә, дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә билгеләнгән тәртиптә тәкъдим итә, матди һәм мораль яктан бүләкләү чараларын күрә, хезмәткәрләрне тармакның мактаулы билгеләре белән бүләкли;

боерык белән министр урынбасарлары, структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген раслый;

боерык белән Министрлыкка беркетелгән процессларны (ярдәмче процессларны) үтәү стандартларын раслый һәм аларның үтәлешен тәэмин итә;

боерык белән нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә министр урынбасарлары, структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм Министрлык хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турындагы нигезләмәне, шулай ук, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән төп күрсәткечләреннән чыгып, стимуллаштыру түләүләре күләмнәрен исәпләп чыгару тәртибен билгеләү турындагы нигезләмәне раслый;

Министрлык өчен билгеләнгән нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләре һәм хезмәт законнары нигезендә ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән контрактлар (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи.

4.3. Министрлыкта дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле булган иң мөһим мәсьәләләр буенча карарлар эшләү төп бурычы булып торган коллегия төзелә.

Коллегиянең составы һәм әгъзалар саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

4.4. Министрлыкта яраштыру советлары, ведомствоара комиссияләр төзелергә мөмкин.

Күрсәтелгән советларның составлары һәм алар турындагы нигезләмәләр министр тарафыннан раслана.

4.5. Министрлыкны үзгәртеп оештырганда архив документлары (идарә итү, финанс-хуҗалык документлары, шәхси состав буенча документлар, вакытлыча


сакланыла торган документлар) билгеле бер тәртиптә хокук кабул итүчегә тапшырыла.

Министрлыкны бетергәндә Татарстан Республикасының Архив фонды документлары, шәхси состав буенча документлар, шулай ук вакыты чыкмаган вакытлыча сакланыла торган документлар билгеле бер тәртиптә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына саклауга бирелә.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 11 июль, 563 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы структурасы




_______________